Балалар өчен Изге Язма

тәкъдим итә

# Кешелек өчен кайгырулар башлануы хакында



Автор: Edward Hughes
Рәсемнәр: Byron Unger; Lazarus
Alastair Paterson
Кемнәр өчен: M. Maillot; Tammy S.
Тәрҗемә ителде: www.christian-translation.com
Гамәлгә ашырылды: Bible for Children
www.M1914.org

BFC
PO Box 3
Winnipeg, MB R3C 2G1
Canada

©2020 Bible for Children, Inc.
Лицензия: Сезнең бу хикәят текстын, сату хокукыннан башка гына, күчермә итеп яки бастырып алу хокукыгыз бар.

РАББЫ АЛЛА ҺӘММӘСЕН БАР КЫЛДЫ! Аллаһы беренче кешене – Адәмне яралткач, ул хатыны Һава белән Гадән бакчасында яши. Алар бик бәхетле була, Аллаһыга сәҗдә итеп, аның барлыгына сөенеп яшиләр, ләкин бер көнне ...





“Аллаһы бакчадагы һичбер агачтан җимеш ашамагыз дидеме?” дип сорый елан Һавадан. “Безгә бакчадагы агачлардан җимеш ашарга ярый,” диде ул.



“Әмма Аллаһы әйтте, бакча уртасындагы агачның җимешләренә кагылмагыз, аларны ашамагыз, юкса үләрсез, диде.” Юк, үлмисез, - дип көлемсөрәде елан. “Аллаһының Үзе кебек булырсың.” Бу агач җимешләренә күптән нәфесем төшкән иде. Ул еланны тыңлап, агач җимешеннән авыз итә.

Аллаһы сүзен тыңламыйча, Һава иренә дә әлеге агачтан җимеш өзеп бирә һәм ашарга куша. Адәмгә: “Юк!  Мин Аллаһы Сүзеннән уза алмыйм”, - диясе булган да бит.





Гөнаһ кылганнан соң Адәм белән
Һава үзләренең шәрә икәнлекләрен күреп ала.
Инҗир яфракларыннан алъяпкыч ясап, үзләрен
каплыйлар һәм, Аллаһыга күренмәс өчен,
бакча агачлары арасына кереп посалар.

Җиләсле кичтә Раббы Алла бакчага килә. Ул Адәм белән Һава кылган гамәлләр турында белеп тора. Адәм барысында да Һаваны гаепли. Һава еланны гаепли. “Елан кәһар иясе булды,” дип әйтә Аллаһы. “Балалар тудырганда хатын-кыз хәзер зур газаплар чигәчәк”, - ди. “Адәм, гөнаһ кылганың өчен, җир туфрагына Минем ләгънәтем төште. Туфрак сиңа күгән белән шайтан таягы үстерер, ашар икмәгеңне маңгай тирен түгеп табарсың.





Аллаһы Адәм белән Һаваны гүзл Гадән бакчасыннан куып чыгара.  Чөнки алар гөнаһ кылды бит, шуңа күрә Тереклекне бар кылучы Раббыдан аерылдылар!



Аларны бакча эченә кертмәс
өчен, Аллаһы утлы кылыч куя.
Раббы Алла, Адәм белән
Һавага тиредән киемнәр
ясап, аларны киемле
итә.  Раббыбыз
бу киемнәрне
каян алган?

Вакыт узу белән, Адәм белән Һава якынлык кыла. Аларның беренче улы Кабил игенче була.  Икенче уллары – Һабил – сарыклар көтүче.  Бервакыт Кабил Раббыга бүләк итеп яшелчәләр китерә.  Һабил Аллаһыга бүләк итеп, көтүендәге иң яхшы берничә сарыкны алып килә. Раббы Һабилнең бүләгеннән канәгать кала.



Кабилнең бүләгеннән Раббы Алла риза булмый. Кабилнең нык ачуы килә.  Раббы Кабилгә болай дип әйтә: “Дөрес әйбер эшләгән булсаң, сине әллә кабул итмәсләр дисеңме?”



Кабилнең ачуы басылмый. Берникадәр вакыттан соң ул кырда Һабилгә ташланып, аны үтерә!



Раббы Алла Кабил белән сөйләшә. “Туганың Һабил кайда?” дип сорый. Белмим, дип алдаша Кабил. “Энемнең җан сакчысы түгел ич мин!” дип җавап кайтара. Аллаһы Кабилгә җәзасын бирә. Аны игенчелек белән шөгыльләнә алмаслык итеп, качак булып яшәргә мәҗбүр итә.



Кабил Раббысы хозурыннан куып җибәрелә. Ул Адәм белән Һава кызына өйләнгән була. Алар тулы бер гаилә үстерә. Тиздән Кабилнең оныклары һәм оныкларының балалары



ул нигез салган калада бик күп була.

Бу арада Адәм белән Һава гаиләсе
бик тиз үрчи.  Ул чорларда кешеләр
хәзерге белән чагыштырганда
озаграк яши торган була.



Уллары Шет тугач, Һава: “Һабил урынына АллаҺы миңа икенче угыл бирде”, - ди. Шет бик тәкъва кеше була, ул 912 ел яши һәм аның бик күп балалары була.



Җир йөзендә адәм балалары үрчегәннән-үрчи
һәм, буыннар алмашынуга карап, тагын
да явызлана бара.  Ниһаять, Раббы
бар нәрсәне юк итәргә карар итә
барлык хайваннарны да, кошларны
да.  Аллаһы кешене
бар кылуына үкенә.



Ләкин бер
бәндәсе генә
Раббы күңеленә
хуш килә …

Ул Нух исемле кеше була. Шет нәселеннән. Нух тугрылыклы һәм гыйффәтле була. Аллаһы юлында йөрүче диндар бәндә була. Ул үзенең өч улын да Аллаһыга сәҗдә кылырга өйрәтә. Хәзер инде Раббы Алла Нухны гадәти булмаганча кулланырга карар кыла.



Кешелек өчен кайгырулар башлануы хакында

Аллаһы Сүзеннән, Изге Язмадан хикәят

урнашкан

Яратылыш 3-6

“Сүзләреңнең күренүе балаларны яктыртып акыллыландыра.” Мәдхия 119:130

# Тәмам

Әлеге Изге Язма хикәятендә Җир йөзендәге барча тереклекне бар кылган һәм Үзенә иман китерүебезне теләгән кодрәтле Аллаһы турында бәян ителә.

Раббыбыз начар гамәлләр кылуыбыз турында белеп тора, Ул аларны гөнаһ дип атый. Гөнаһның җәзасы – үлем. Ләкин Аллаһы сезне шулкадәр ярата ки, гөнаһларыгыз өчен җәзаланырга дип бердәнбер Улы Гайсәне хачта үтертү өчен җибәрде. Шуннан соң Гайсә үлеп терелде һәм Күккә ашты! Гайсәгә ышансагыз, гөнаһларыгызны кичерүе турында сорагыз, Ул моны эшләр! Ул килер һәм сездә яшәр, һәм сез дә мәңге Аның белән бергә булырсыз.

Моның хак булуына ышансагыз, Аллаһыга болай диегез: Хөрмәтле Гайсә, Синең Раббы булуыңа һәм гөнаһларым хакына һәлак ителү өчен кеше булып яралтылуыңа һәм хәзерге вакытта исән булуыңа ышанамын. Зинһар өчен, тормышыма үтеп кер, мин яңа тормыш башлап, кайчан да булса Синең белән мәңге бергә була алсын өчен, гөнаһларымны ярлыка. Балаң күк, Сиңа сәҗдә кылып, Сиңа иман китереп яшәргә ярдәм ит. Амин.

Изге Язма укы һәм көн саен Аллаһы юлында бул! (Яхъя 3:16)